СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ**
**31.10.2024**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 429**

Зеленодольск муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләренә әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә Зеленодольск муниципаль районы вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Зеленодольск муниципаль районында бюджет процессы турындагы нигезләмә нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. 1 - 2 нче кушымталарда каралганча, Зеленодольск муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләренә әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә Зеленодольск муниципаль районы вәкаләтләренең бер өлешен тапшырырга.

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына 1-2 нче кушымталарда күрсәтелгән әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында Зеленодольск муниципаль районы авыл җирлекләре Башкарма комитетлары белән килешүләр төзергә.

3. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан 1-2 нче кушымтада күрсәтелгән Зеленодольск муниципаль районы составына керүче Зеленодольск муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләре бюджетларына бирелә торган финанс чаралары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында интернет челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Советы рәисе** **М. П. Афанасьев**

Зеленодольск муниципаль районы
Советының
2024 елның 31 октябрендәге
429 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Зеленодольск муниципаль районы
Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы
составына керүче «Татарстан Республикасы Күгеш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлегенә әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге
вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыра:**

- Зеленодольск муниципаль районының Күгеш авыл җирлегендә калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннарын бетерүне.

Зеленодольск муниципаль районы
Советының
2024 елның 31 октябрендәге
429 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы**
**составына керүче «Татарстан Республикасының Большие Ключи авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенә әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыра:**

- «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Большие Ключи авылында Комсомол урамы буенча күлләрне чистартуга проект-смета документациясен эшләүне».